80

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № I-3**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 23 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Уставының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 15.10.2010 № I-4 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә үткәрергә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар 2025 елның 23 сентябреннән 2025 елның 13 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык бистәсе штп, Ленин ур., 48 й., каб.№23. Кабул итү вакыты: 8:00 дән 12:00 гә кадәр һәм 13:00 дән 17: 00 гә кадәр (ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш). Элемтә өчен телефон: 8(84361) 22-189 (Шавалеева Светлана Геннадиевна), факс: 23-012. E-mail: Svetlana.Shavaleeva@tatar.ru.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составын (алга таба – конкурс комиссиясе) Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләп кую турында» 2023 елның 25 маендагы 332 номерлы, «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен

конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында»2024 елның 28 ноябрендәге 921 номерлы; «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләп кую турында "Татарстан Республикасы Рәисе Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 4 сентябрендәге 708 номерлы Указларын исәпкә алып кушымта нигезендә расларга.

3. Конкурс комиссиясенә 2025 елның 14 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына кандидатлар турында мәгълүмат тапшырырга.

4. Конкурс үткәрү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турындагы хәбәрне «Авыл офыклары»район газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы — Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль район
Совет карарына кушымта
23.09.2025 дән №I-3

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| № | Ф.И.О. | Эш урыны, вазифасы | Кем билгеләнде | Комиссия составнда статусы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Вафин Фәрид Мансур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия рәисе |
| 2. | Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры | Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан | Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Шавалеева Светлана Геннадиевна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия сәркатибе |
| 4. | Сөнгәтуллина Лидия Фаварис кызы | Татарстан Республикасы Рәисенең территорияләр белән эшләү идарәсенең баш киңәшчесе | Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан | Комиссия әгъзасы (килешү буенча) |
| 5. | Самаренкин Дмитрий Анатольевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, "Казан май комбинаты" акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе | Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан | Комиссия әгъзасы (килешү буенча)) |
| 6. | Мингарипова Гүзәл Ильсур кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы урынбасары | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия әгъзасы |